РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_15_» ___05___ 2026 ел № 530

2026 елның II кварталына
Ютазы муниципаль районы буенча
торак мәйданының 1 квадрат метрының
уртача базар бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарына, торак урыннарына мохтаҗ дип танылган гражданнарга исәпкә кую һәм бирү максатларында гражданнарны аз керемлеләр дип тану тәртибен билгеләү буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен методик тәкъдимнәр нигезендә, шулай ук РФ Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Ютазы муниципаль районында «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгы тарафыннан торак урыннарның 1 квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшерену нәтиҗәләре буенча, 2026 елның II кварталына Ютазы муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының 1 квадрат метры бәясе нормативын 53 571 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм

«Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
8(85593)2-42-05